ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ПИСЬМЯНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гагарина, д.5, п.Подлесный,
Лениногорский район, 423257
Тел./факс: (85595) 3-87-94
E-mail: Pism.Len@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ПИСМӘН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Гагарин урамы, 5нче йорт,
Подлесный поселогы,
Лениногорск районы, 423257
Тел./факс: (85595) 3-87-94
E-mail: Pism.Len@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел №2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Савочкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Савоч кино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 14 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге Савочкино территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы сугышы һәм хәрби хәрәкәт ветераннарының тол хатыннарыннан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

- урамнарны яктыртуны оештыру;

-авыл җирлеге юлларын ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларны карап тоту һәм ремонтлау эшләре).

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный авылы, Гагарин урамы, 5 нче йорт, Подлесный авылы, Гагарин урамы, 1б йорт, Иске Писмән авылы, Үзәк урамы, 50 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов